«РАСЛЫЙМ»

«Сәләт» ТРЯИФ

генераль директоры

_____________Җ. Ш. Сөләйманов

(Әдип Әлмир)

15 сентябрь, 2020 ел

**«Сәләт ВикиМәктәбе» проектын оештыру**

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

1. Проектның оештыручылары

«Сәләт ВикиМәктәбе» проекты Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды һәм Сәләт клубы тарафыннан Викимедиа җәмгыятенең татар телле катнашучылары төркеме һәм «Викимедиа РУ» табышсыз партнёрлыгы ярдәмендә оештырыла.

2. Проектның максаты һәм бурычлары

Проектның максаты:

- Татар телле сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне Викимедиа замана белем платформасы белән таныштыру һәм аның мөмкинлекләрен куллануны өйрәтү аша татар телендәге мәгълүмати контентны үстерү.

Проектның бурычлары:

- Сәләт хәрәкәте вәкилләрен үз проектларында Вики-мохит биргән мөмкинлекләрне куллана алуларына әзерләү;
- бүгенге җәмгыятьтә интеллект һәм мәгълүматны беренче урынга кую идеяләрен алга этәрү;
- Татар телле яшьләрдә мәкаләләр язу һәм иҗтимагый активлык дәрәҗәсен арттыру;
- Татарстан Республикасы яшь лидерларында позитив иҗтимагый һәм профессиональ имидж булдыру.

## 3. Проектта катнашучылар

Проектта 14-25 яшьтәге татар телле яшьләр катнаша. Проектка Татарстанда, Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче интернетка чыгу мөмкинлеге булганнар кушыла ала.

## 4. Проектны уздыру шартлары, тәртибе һәм вакыты

Проект сезоннар буенча оештырыла (көзге, язгы һәм җәйге) һәм 5 этапта уздырыла:

1-нче этап – «Гаризалар кабул итү».

Катнашучылар гаризаны расланган Google-форма ярдәмендә тутыралар һәм шуның белән проект чараларында катнашырга ризалык белдерәләр.

Вакыты – **ел дәвамында**.

2-нче этап – «Викимедиа проектлары мөмкинлекләрен Сәләт проектларына кертү».

Әлеге мөмкинлекләр аеруча М.И. Мәхмүтов исемендәге «Фәнсар» мәктәбе, «Sanak-lab» уку-укыту лабораториясе, Сәләтнең җәйге аланнары һәм «Сәләт» Клублары эшчәнлегенә кертелә.

Вакыты – **ел дәвамында**.

3-нче этап – «Уку-укыту программасы».

Катнашучылар онлайн һәм оффлайн рәвештә уку-укыту курсларын үтә. Программа Викимедиа проектларында катнашу кагыйдәләрен өйрәнүдән гыйбарәт. Программа ахырына якынлашканда, катнашучылар өчен сынау чарасы үткәрелә.

Нәтиҗәләр ясаганда, программаны узган яшьләргә проект таныклыгы бирелә.

Вакыты – **сезонның беренче ае.**

4-нче этап – «Гамәлият».

Катнашучылар алган күнекмәләрен гамәлдә куллана алу мөмкинчелеген тудыру максатыннан, алар өчен Татарстанның һәм күрше төбәкләрнең истәлекле урыннарына экскурсияләр, кызыклы очрашулар оештырыла. Шулай

ук Викихәбәрләрдә язучы катнашучылар төрле чаралар хакында мәкаләләр әзерли. Проект активистлары Викимедиа оештыручы марафоннарда һәм бәйгеләрдә катнаша. Гамәлияткә әлеге активлыклар керә: вики-сәфәр, мәкалә конкурслары.

Оештыру комитеты, катнашучылар активлыгын күзәтеп, иң алдынгыларын илкүләм һәм халыкара чараларына җибәрергә мөмкин.

Вакыты – **сезонның икенче ае**.

5-нче этап – «Җәйге уку-укыту кампаниясе».

Халыкара «Сәләт» уку-укыту форумнары мәйданчыкларында һәм Сәләт аланнарында катнашучы сәлкешләр кыскартылган вики-программалар, бер мәртәбәле остханәләр ярдәмендә Викимедиа проектларына җәлеп ителә.

Вакыты – **июнь-август айлары.**

Көтелмәгән очраклар килеп чыкканда Оештыру комитеты проектның уздыру этапларын үзгәртергә мөмкин.

## 5. Проектның Оештыру комитеты

Оештыру комитеты Проектны әзерләү һәм уздыру өчен Сәләт клубы әгъзаларыннан, «Сәләт» фонды һәм «Сәләт» яшьләр үзәге хезмәткәрләреннән һәм тәҗрибәле викимедиачылардан туплана. Оештыру комитетының составы ТРЯИФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Оештыру комитеты:

- проект оештыруны һәм уздыруны әзерли;
- проект уздыруның һәр этабын администрацияли;
- проект программасының һәр этабын уздыруны билгели һәм раслый.

## 6. Проектның Остазлар шурасы

Викимедиа проектларында катнашучыларның эшләрен күзәтеп тикшерү максатыннан Остазлар шурасы булдырыла. Аның составы «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Остазлар шурасы составына Сәләт активистлары, Викимедиа проектларының тәҗрибәле кулланучылары, мәгариф хезмәткәрләре керә.

Остазлар шурасы өстәмә рәвештә проектның конкурсларында махсус бүләкләр һәм номинацияләр билгели ала.

## 7. Элемтә өчен мәгълүмат

Оештыру комитеты адресы: Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт, 5-нче бүлмә (Сәләт йорты).

Белешмәләр өчен телефон: +7-987-405-18-94 (Хәбил Сәхабиев, «Сәләт ВикиМәктәбе» проекты координаторы)